| | | |
|---|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ГЛАВА СЕЛЕНГУШСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>НУРЛАТСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>СӘЛӘНГЕШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШЛЫГЫ |

| | |
|---|---|
| ПОСТАНОВЛЕНИЕ<br>“10” ноябрь 2021 ел | КАРАР<br>№ 3 |

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Сәләнгеш авыл җирлегенең Зүзәй авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Сәләнгеш авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Сәләнгеш авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2021 елның 23 ноябрендә 12 сәгать 00 минутка Зүзәй авылы Үзәк урам 12 нче йорт янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Сәләнгеш авыл җирлеге Зүзәй авылында Үзәк урам буенча 2-52, Озерная урамы буенча 7-23, Шоссейная урамы буенча 3-27 нче йортларда яшәүчеләр өчен гражданнардан үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Халык җыенын уздыруны билгеләргә.

2. Халык җыенын үткәрү һәм оештыру Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Сәләнгеш авыл җирлеге башлыгы һәм Башкарма комитеты тарафыннан тәэмин ителә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Сәләнгеш авыл җирлегенә керүче Зүзәй авылы территориясендә яшәүче балигъ булган һәр кешедән, 1 гр инвалидлардан тыш, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, 2022 елда 1000 (бер мең) сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:
- Сәләнгеш авылындагы кыр урамыннан Сәләнгеш авылы янындагы зиратка кадәр юлны ремонтлау;
- Зүзәй авылында су белән тәэмин итү объектларын ремонтлау һәм төзекләндерү.

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (игълан итәргә) һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Нурлат

муниципаль районы Зүзәй авылының мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча урнаштырырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Сәләнгеш авыл җирлеге башлыгы А.Н. Пинин